# Ислам нуры

اسلام نوری

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 22 (698) 27 ноябрь 2019 ел (1441, Рабигуль-әүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


## Җәннәт әниләрнең аяк астында



Берәү Мөхәммәд (с.г.в.) янына килгән дә: «Йә Рәсүлуллаһ, бу дөньяда мин кемгә иң зур хөрмәт һәм ихтирамны күрсәтим?!» – дип сораган. Моңа каршы пәйгамбәр (с.г.в.), әни кешегә, ди. «Аннары кемгә?» - дигән сораугa янә, әниеңә, дигән җавапны ала. Өченче тапкырында да пәйгамбәребез кабат, әниеңә, ди. Ә дүртенчегә: «Тагын кемгә?» – дип сорагач, «Әтиеңә», диелә. Сәхабәләр вакытында шундый хәл булган. Бер сәхабә үзенең әнисен аркасына күтәреп хаҗга алып барган һәм бер галимнән, әни алдындагы бурычымны үтәдемме инде, дип сораган. Галим исә, син бу эшең белән анаңның сине тапканда тулгак вакытындагы бер авырту мизгелен дә түләмәдең, дигән.

Пәйгамбәр янына бер кеше килгән дә, әти-әнием дөньядан киттеләр, тик мин аларга хәзер дә берәр изгелек эшли аламмы, дип сораган. Мөхәммәд (с.г.в.)" Биш төрле изгелек кыла аласың", - ди. Аның беренчесе – аларның урыны җәннәттә булсын дип, дога кылып тору. Икенчесе – истигъфар кылу, ягъни әти-әниемнең гөнаһларын гафу ит дип Аллаһыдан сорау. Өченчесе – әти-әниеңнең исән вакытларындагы берәр хыялы тормышка ашмаган булса, әгәр дә хәерле яхшы хыял икән, аны гамәлгә ашыру. Дүртенчесе – әти-әни кем белән дус булган булса, аларны хөрмәт итү, алар белән аралашып тору. Бишенчесе – әти-әни ягыннан булган кардәшләр белән яхшы мөнәсәбәттә булу. Болар үтәлсә, аларның рухлары тыныч булачак.

## Чаллы яңалыклары



Чаллының "Аш-Су" ресторанында Гүзәл Вәлишинаның "Хыял кызы" дип аталган, хатын-кызлар өчен никах күлмәкләре күргәзмәсе булды. Чакырылган кунаклар төрле дин вәкилләрен тәшкил итте. Алар арасында танылган шәхесләр һәм эстрада йолдызлары да бар иде. Чара "Утыз-Имәни" мәчете имамы Инсаф хәзрәт Сәүбановның кыскача вәгазе һәм догасы белән башланып китте. Күргәзмә дәвамында Гүзәл Вәлишина тарафыннан тегелгән 30 никах һәм шулай ук "Wedding" туй салонының 6 туй күлмәкләре күрсәтелде. Модель хатын-кызлар чыгышлары арасында кунаклар өчен кыйммәтле бүләкләр белән уеннар уздырылды, эстрада йолдызлары чыгышлары һәм мастер- класслар үткәрелде. Шулай ук теләге булган кунаклар "көзге кешеләр" һәм танылган шәхесләр белән фотога төшә алдылар. Әлеге күргәзмә бик күркәм үтте. Килгән кунаклар заманча матур һәм шул ук вакытта Ислам диненә туры китереп тегелгән тыйнак никах күлмәкләренә соклануларын белгерделәр.

***

Чаллы мәчетләрендә мәүлид аена багышланган чаралар дәвам итте. "Рамазан" һәм "Ихлас" мәчетләрендә дә әлеге ай хөрмәтенә кичәләр үткәрелде. "Рамазан" мәхәлләсе аны кичке намаздан соң аш мәҗлесе рәвешендә уздырды. Чара кунаклары итеп шәһәребез имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт, аның урынбасары Фоат хәзрәт һәм башка мәчет имамнары да чакырылган иде. Мәҗлес мәчет имам-хатыйбы Илдар хәзрәтнең җыелган халыкны мәүлид ае белән тәбрикләве һәм мәчет эшчәнлегендә актив катнашкан кешеләргә үзенең рәхмәтләрен белдерүе белән башланып китте. Соңрак "Ихлас" мәчете имам-хатыйбы Илгиз хәзрәт Коръән укып дога кылынды. Шулай ук чара дәвамында Әлфәс хәзрәт "Рамазан" мәчетенең актив карты Миңнулла абыйны юбилее белән котлады. Мәҗлес төнге намазга чаклы дәвам итте.Төнге намаздан соң "Ихлас" мәчетендә Мөхәммәд Пәйгамбәргә (с.г.в.) багышланган "Галәмнәрнең рәхмәте" дип аталган викторина узды. Шәһәребез мөхтәсибәте тарафыннан мәүлид аена багышланган, "Минем Пәйгамбәрем" дип аталан видео-роликлар һәм "Пәйгамбәрем шәҗәрәсе" дип исемләнгән рәсемнәр конкурсларына нәтиҗәләр ясалды.

"Туфан" мәчетендә дә мәүлид аена багышланган аш мәҗлесе үтте. Мәҗлес барышында шәһәребез имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин килгән кунаклар алдында Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.в.) карата мәхәббәт хакында һәм мәүлид ае хөрмәтенә уздырылган чараларның динебезне ныгытуга керткән файдасы турында сөйләп үтте. Мәчет имам-хатыйбы Равил хәзрәт Нуруллин әлеге чараны әзерләргә булышкан кешеләргә үзенең рәхмәтләрен белдерде. Мәҗлес Коръән укып дога кылу белән тәмамланды.

Сидоровка бистәсе "Ихлас" мәчетендә дә аксакаллар белән бергә мәүлид аена багышланган кичә узды.

Җәмигъ мәчетендә дә бик күркәм мәҗлес узды. "Нәселемне Дингә чакырам" дигән зур проектка нәтиҗә ясалды. Мәҗлестә мөхтәсибәтнең укыту һәм дәгъват бүлеге җитәкчесе Илдар хәзрәт, Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы Рәис хәзрәт, Җәмигъ мәчете имамы Мөхәммәд хәзрәт һәм мәчет активы катнашты. Иң зур нәтиҗәләргә ирешкәннәргә бүләкләр тапшырылды, вәгазьләр сөйләнде.



**Нияз ГАЗИЗОВ.**

## ТР МДН хәбәр итә



Рабигуль-әүвәл аеның 23нче көнендә, Кыргызстан республикасы башкаласы Бишкәк шәһәрендә "Православие һәм Ислам - тынычлык диннәре" халыкара конференциясе ачылды. Аның мәртәбәле кунакларының берсе итеп Татарстан мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин чакырылды. Әлеге фәнни җыенда шулай ук мөфтинең урынбасары, Россия ислам институты ректоры Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин һәм Болгар ислам академиясе ректоры Данияр Абдрахманов катнашты.

***

Рабигуль-әүвәл аеның 24нче көнендә, Болгар ислам академиясендә «Россиянең мөселман дини-илаһият мәктәбен торгызу һәм үстерү шартларында Ислам гыйлеме өлкәсендә тикшеренүләр тәҗрибәсе» дип исемләнгән халыкара фәнни-гамәли конференция үз эшен башлап җибәрде. Форумга Россия, якын һәм ерак чит илләрдән белгечләр һәм экспертлар җыелды. Фәнни форумны Болгар ислам академиясе, М.В.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты белән берлектә, РФ Фән һәм югары белем министрлыгы, Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте, РФ мөселманнары Диния нәзарәте һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте ярдәме белән оештыра.

***



Рабигуль-әүвәл аеның 24нче көнендә, Казанда "Рәшидә" Коръән-хафизлар әзерләү үзәгендә ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча Татарстанның һөнәри мөселман уку йортлары (мәдрәсәләре) арасында нәзарәт тарафыннан оештырылган беренче республика олимпиадасы узды. Ярышларда Чаллы, Әлмәт, Казан, Кукмара, Буа, Мамадыш һәм Ютазы районнары шәкертләре катнашты. Беренче урын алучыларга айпадлар, икенчегә – ноутбуклар, өченчегә – мобиль телефоннар тапшырылды. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе шәкерте Шамил Имамов исә Ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча республика олимпиадасының абсолют җиңүчесе булды. Аңа хаҗга юллама тапшырылды. Ул – Ульян өлкәсе Мәләкәс (Димитровград) шәһәреннән килгән 22 яшьлек татар егете, мәдрәсәдә өченче курста белем ала.

# Хыянәтче иптәш

Газиз кардәшем! Дөньяда яшәгәндә без һәрвакыт нәрсәдер саныйбыз, хисаплыйбыз. Җыйган акчаларыбызны саныйбыз, кылган изге эшләребезне санап, үзара мактанышабыз. Санау, хисаплау өчен яңадан-яңа алымнар кулланабыз, ачышлар ясыйбыз, җиһазлар уйлап табабыз. Оешмаларда көн, атна, ай, квартал, еллык отчетлар үткәрәбез. Тиешле нәтиҗәләр ясап, тиешле чаралар күрергә карар кылабыз. Кибет хуҗасы көнлек керемне карап, үз эшчәнлегенә бәя бирә. Сәүдәсенә үзгәрешләр кертә, керемне арттырырга тырыша. Даими хисап алып барган оешма өчен ревизия дә куркыныч нәрсә түгел. Без, кешеләрнең күпме гомере шушы хисаплар, отчетлар белән үтә. Ләкин шул ук вакытта кешелек өстендә торган янә бер хисапны онытып җибәрергә ярамый. Көннәрдән бер көнне, адәм баласы үзен юктан бар итүче Раббысы каршына басып, дөньялыкта кылган һәр эше, әйткән һәр сүзе, ашаган һәр ризыгы, кулланган һәр нигъмәте өчен җавап тотачак. Ул көннең хисабы - иң олуг хисап, ул имтихан, иң олуг имтихан булачак. Шиксез, ул хисап көненә гомере дәверендә хәзерләнгән кешегә генә Аллаһ җиңеллек бирә. Ни кызганыч, шушы хисаптан кешеләрнең күбесе гафил.

Газиз кардәшем. Бүген, ялгызың калып, әйткән сүзләрең, кылган эшләрең хакында уйландыңмы? Бүген, изгелекләреңне санаган кебек, кимчелек-хаталарыңны да танырга теләдеңме? Бүген, кылган изгелекләрең хакында да уйландыңмы? Баксаң, күбесендә рия, мактану, үз-үзеңне канәгатьләндерү кебек таплар табарсың. Бүген, кичкырын, үзеңә көнлек ревизия үткәреп кара, нинди нәтиҗәләргә килерсең икән? Йөргән юлларың кимчелекләр белән капланган, аткан сүзләрең яман, буш сүзләр белән каралган... Бу кадәр авыр йөкләрне күтәреп Раббың каршына ничек килерсең? Аллаһ Тәгалә: «Һәркем үзенең иртәгәсе көнендә Раббысы белән очрашуга нәрсә хәзерләгәнен карасын», - диде. (Хәшер сүрәсе,18).

Гомәр ибн Хаттаб р.г. әйтте: «Хисап кылыгыз үзегезгә, хәтта сезгә хисап кылганчы. Үлчәгез үзегезне, хәтта сезне үлчәгәнче. Бүген үзегезгә булган хисап иртәгәсе буласы хисапны җиңеләйтә. Кыямәт көне өчен үлчәнегез. Ул көнне сезне үлчәрләр, эчегездә булган бер серегез дә качып калмас».

Газиз кардәшем, безгә кадәр яшәгән хөрмәтле затлар шулай булдылар. Аллаһка изгелекләр белән якынайдылар. Үз-үзләрен хаталар өстеннән хисап кылдылар. Әбү Бәкер, күңеле нечкә иде, күп елады һәм: «Елагыз, еламасагыз, сезнең өчен еларлар», - диде. Үсеп утырган үсемлеккә карап: «Шушы үсемлек булып, ашалып юкка чыксам иде», - дип, Олуг хисаптан курыкты.

Гомәр ибн Хаттаб, Тур сүрәсен укып, Аллаһның: «Тәхкыйк, Раббыңның газабы һичшиксез булачактыр», – дигән сүзләренә җиткәч, елап җибәрде. Ул шулкадәр елады, хәтта авырып китте. Көн-төн шул аятьне укып елады, хәтта елаудан йөзендә җыерчык-сызыклар барлыкка килде.

“Җәһәннәмдә бер генә кеше калыр, - дигән хәбәр килсә, валлаһи, ул кеше мин дип уйлар идем”, - диде.

Госман ибн Гаффән р.г. кабер янына баскач, елады, хәтта күз яшьләре сакалын чылатты. «Җәннәт һәм ут арасында калып, кайсысына керергә әмер буласын белми торудан куркамын. Кайсысына китәсемне белгәнче, туфракка әйләнеп юк булсамчы», - диде.

Гали ибн Әби Талиб күп елады, үзенә хисап кылды. Аеруча ике нәрсәдән курыкты: озын киләчәккә өметләр һәм нәфескә иярү. «Озын киләчәккә өметләр — ахирәтне оныттыра. Нәфескә ияру — хаклыктан тайпылдыра», - диде.

Бездән иманлырак, изге эшләрдә күпкә алданрак булган сәхабәләр бездән никадәр артыграк куркуда булдылар. Безнең иманыбыз да зәгыйфь, изгелекләребез дә күпкә аз, гөнаһларыбыз да артык, әмма куркуыбыз бик түбән.

Аллаһның йөрәктәге вәгазьчесе Пәйгамбәребез с.г.в. әйтте: «Аллаһ туры юлга мисал итеп, ике ягыннан ике дивары булган бер юлны китерде. Диварларда ачык ишекләр, ишекләрдә — пәрдәләр. Юл өстендә бер эндәшүче: «Әй кешеләр, барыгыз да юлдан гына барыгыз, кырларга борылмагыз!» - дип кисәтеп тора. Әгәр берәрегез ул ишекләрне ачарга теләсә, эндәшүче шундук: «Хәсрәт сиңа, ишекне ачма! Ишекне ачсаң, кереп китәсең», - дия. Юл — ислам, пәрдәләр — Аллаһ куйган чикләр, ачык ишекләр — Аллаһның хәрамнары. Өстән эндәшеп торучы — һәр мөселманның да йөрәгендә булган Аллаһның вәгазьчесе». (Әхмәд, Хәким. Сахих хәдис).

Син, кардәшем, йөрәгең түрендә утырган Аллаһның вәгазьчесен ишетәсеңме? Син, кардәшем, Аллаһ куйган чикләрне саклап, хәрамнардан ерак торасыңмы? Әллә, Аллаһның дошманнары һәм үзеңнең дошманың өстеннән җиңү яуладым дип уйлыйсыңмы? Аллаһ Тәгалә әйтте: «Дөреслектә, шайтан сезнең өчен дошман, аны дошман күрегез. Ул үзенә иярүчеләрне бары тик җәһәннәмнең ялкынлы утына гына чакыра».

Халид ибн Мәгдән р.г. әйтте: «Һәрбер бәндәнең йөзендә ике күзе бар, ул алар белән дөнья эшләрен күрә. Калебендә ике күзе, алары белән ахирәт эшләрен күрә. Аллаһ бәндәсенә хәерлелек теләсә, бәндәнең калеб күзләрен ача. Ул күзләр белән бәндә Аллаһ вәгъдә иткән яшерен нәрсәләрне күрә».

Газиз кардәшләрем, дустыңның хыянәтче икәнен белсәң, күздән һич төшермисең. Нәфес тә хыянәтче иптәш кебек, һәрчак тикшереп тормасаң, малыңны алып кача. Имам әл Җәүзи әйтә: «Шунысы сәер, күп акча ияләре үзләренең малларына ялган (фальш) акча керүдән куркалар, ә ул акчаны ясаучы тыныч. Пәйгамбәребез, Хүзәйфә исемле сәхабәсенә монафыйкларны әйткәч, Гомәр ибн Хаттаб аның янына килеп: «Мин алардан түгелме?» – дип сорады. Ибн Әби Мүлкийә әйтте: «Пәйгамбәрнең утыз сәхабәсен белдем, барысы да үзләре өчен монафыйклыктан курыкты һәм берсе дә: «Иманым Җәбраил һәм Микәилнеке кебек», — димәде”.

Әй мөселман кардәшем! Имам Ибн Каим әйтә: «Кем сәхәбәләрнең тормышлары белән кызыксына, аларны күп гамәл белән күп куркуда күрә. Без барыбыз да гел киметүдә, ягъни салкын караш һәм тынычлыкта». Ибн Каим үзе һәм яшәгән гасыры хакында шулай дигәч, безгә үзебез һәм гасырыбыз турында нәрсә әйтәсе кала?

Кардәшем, гамәлең алдыннан уйла, ул гамәлең Раббың өченме? Гамәлең артыннан уйла, Аллаһ өчен кылдыңмы?

Үзеңә хисап кылу ни рәвештә соң? Имам Ибн Каим нәфесне хисаб кылуны түбәндәгечә аңлата:

Беренчедән: Хисапны Аллаһының безгә әмер иткән фарызлардан башларга. Аларда берәр кимчелек кенә күренсә дә, тизрәк ул кимчелекне төзәтергә.

Икенчедән: Аллаһ тыйган хәрамнарда хисап. Әгәр кеше берәр хәрамга керә башлавын сизеп алса, шундук тәүбә-истигъфәр кылып, аны изге гамәлләр белән алыштырырга тиеш.

Өченчедән: Гафиллеккә каршы көрәш йөзеннән, нәфесне һәрвакыт Аллаһны зикер итүгә этәреп тору. Аллаһ булган калебтә шайтанга урын юк. Аллаһыны оныткан калебнең ишекләре шайтан өчен ачык.

Дүртенчедән: Тән хәрәкәтләрен, тел сөйләгән сүзләрне, аяк адымнарын, кул сузылуларын, күз карашларын, колак тыңлаган нәрсәләрне һәрдаим хисабконтрольда тоту. “Син моның белән нәрсә теләдең? Моны кем өчен кылдың? Кем ризалыгын алырга омтылдың?”

Кадерле дустым! Үз-үзенә барча хәрәкәтләрдә, барча ял вакытларында, барча мизгел һәм адымнарда хисап кылу һәрбер зирәк акыллы мөэминнең бурычыдыр.

Гомер сулышларының һәркайсысы кыйммәтле бер таш кебек. Ул ташлар белән табышы килүдән һичтуктамас хәзинәләр сатып алырга мөмкин. Бу кыйммәтле ташларны файдаланмый калдыру, яки киресенчә, алар белән һәлакәткә илтә торган нәрсәләр сатып алу зур хәсрәттер. Бу эшне иң ахмак кеше генә булдыра. Бу хәсрәтнең хакыйкатен Кыямәт көне, үкенеч көне күрсәтәчәк. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Ул көнне, һәр кеше кылган изгелеген үз каршында табар. Бозыклык кылучы явыз эшләре белән үзенең арасын бик ерак булуны теләр». (Әлү Гыймран, 30)

Хөрмәтле дустым! Көннәрдән бер көнне, үз–үзләренә хисаб кылучыларның берсе үзенә хисап кыла, аңа ул көн 60 яшь була. Тормыш иткән көннәрен санап караса, 21500 көн килеп чыга. Бу санны күреп аның күзеннән яшьләр бәреп чыга. «Әй кайгы миңа, Раббым каршына 21 000 гөнаһ белән бараммы? Көненә меңләгән гөнаһлар булса нишләрмен?!”

Фүдайль бер кешедән: “Сиңа ничә яшь?”-дип сорады. Ул: “Алтмыш”,- диде. Фүдайль: “Алтмыш ел Раббыңа таба барасың, бәлки тиздән килеп тә җитәрсең”, - дип әйтте. Чыннан да, кардәшләрем, үткән һәр елыбыз, ай вә көнебез, һәр сулышыбыз Раббыбызга якынайта. Галәмнәрнең Раббысы белән очрашуга нәрсә хәзерләдек без? Әй, егерме көз уллары, күпме дусларыгыз инде ахирәткә юл тотты. Әй, утыз көз уллары, Әй кырык көз уллары, сабыйлык китте, ләкин сез һаман уенкөлке кулында. Әй, илле көз уллары, гасырның яртысына җиттегез, ләкин һаман шәһвәт юлында. Әй, алтмыш көз уллары, чәчләрегез агарды, ләкин гафиллек китмәде.

Газиз кардәшем, утыр, сана, хисаплап кара. Күпме намазыңны калдырдың?... Күпме җомгалардан сәбәп таптың? Күпме сәдакаларны комсызлыгың кесәңдә калдырды? Күпме хаҗлар синсез үтеп бара? Күпме изгелеккә ялкау булдың? Күпме яманлыктан битараф калдың? Телең күпме бозык сүзләр сөйләде? Газиз ата-анаңның күпме күз яшен агыздың? Күпме ятимнәрне рәнҗеттең? Күпме кешеләргә золымлык кылдың? Күпмеләрен сүктең, гайбәтләрен саттың? ...

Үткән көннәр белән күңелләрне юатабыз, үткән һәр көн әҗәлгә илткәнен онытабыз.

Ахырың килгәнче изгелек кыл, гафил булма, бәхет тә, хәсрәт тә гамәл эчендә - онытма.

**Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН,**
**Казанның Идел буе һәм Вахитов районнары имам-мөхтәсибе.**

## Пәйгамбәребез киңәшләре

*Һәрвакыт чиста ризык аша.*

*Артык кайнар һәм артык салкын ризык ашама.*

*Озак чәйнәп, ашыкмыйча аша.*

*Ашау алдыннан һәм соңыннан кулларыңны ю.*

*Артыгын ашама, гел ашыйсың килеп торсын.*

*Ашаганда артык күп су эчмә.*

*Кыш көннәрендә – майлы, җәй көннәрендә җиңелрәк ризык аша.*

*Йөзем, хөрмә, зәйтүн Аллаһыга шөкер итү өчен сиңа сихәт бирер.*

*Арыганда баллы ризыклар аша.*

*Ватык савыттан ашама.*

*Ялгыз ашамаска тырыш.*

*Ашап бетергәч, дога укып, шөкер кыл.*

*Ай саен өч көн ураза тот.*

*Бал аша, ул мең авыруга дәвадыр.*

*Дәрәҗәдән коры калмас андый кеше.*

* *Үзен иркәләгәнне бер көн дөнья типкәләр*

* *Үзенә ышанган — йокыдан торып киткән,*
*Әтәчкә ышанган ятып калган.*

* *Үзеңә үзең каты тор,*
*Чыгымчы атка йөгән ор!*

## МИНЕМ ФИКЕР



***Рәис хәзрәт Әхмәтов**, Чаллының “Сөембикә” мәчете имам-хатыйбы:*

Барча сәнәләребез, мактауларыбыз бер Аллаһка булсын! Мөхтәрәм кардәшләрем, без сөйләмебездә бик еш кына гөнаһ сүзен кулланабыз. Ә нәрсә соң ул гөнаһ? Ул безнең Аллаһ каршындагы хакыбыз. Аллаһ безгә кушкан, ягъни фарыз иткән гамәлләр бар. Аллаһы Тәгалә безне тыйган гамәлләр бар. Әгәр дә без Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәмибез икән, без Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһлы. Әгәр дә без Аллаһы Тәгалә тыйган гамәлләрне кылабыз икән, бу да Аллаһ каршында гөнаһ. Димәк, кеше үзенә-үзе бәя бирә алмый икән, бу - Аллаһка хас билгеләмә. Күпме кеше бүгенге көндә бәяне үзләренә-үзләре куеп йөри. Еш кына намазга чакырганда шундый сүз ишетергә туры килә: минем бер гөнаһым да юк, намазны гөнаһлылар укысын, диләр. Зур саташу! Әлбәттә, шайтан үз эшен яхшы башкара. Шундый фикерне кешеләрнең калебенә кертә. Мондый уй үзе үк гөнаһлы. Син инде үзеңне ислам дине вәкиле дип санайсың икән, иман, намаз, ураза, зәкәт, хаж - болар мәҗбүри, син телисеңме-теләмисеңме, боларны һичшиксез башкарырга кирәк. Әле шуның өстенә кеше хаклары, хәләл һәм хәрам бар. Шәригатебез билгеләгәнчә, гөнаһларыбыз Кыямәт көнендә Аллаһ каршында үлчәүгә куелачак. Аларны иңебездәге фәрештә язып бара. Син үзеңә үзең бәя бирә алмыйсың. Шуның өчен, кардәшем, мондый фикердән тәүбә ит.

Икенче төр кешеләр «мин нык иманлы» дип белдерәләр. Үзләре менә мин алда санап киткән фарызларның берсен дә эшләмиләр. Ничек бер гамәл дә кылмыйча, үзеңне бик иманлы кешегә санап була икән, белмим. Иман бит - Аллаһның барлыгын, берлеген кабул итү. Аның китапларын, пәйгамбәрләрен, фәрештәләрне, тәкъдирне, ахирәтне кабул итү. Ахирәткә иман китердең икән, димәк, син тереләчәксең, мәхшәр мәйданына киләчәксең. Синең гамәл дәфтәрләреңә язылганнарны сиңа бирәчәкләр. Син аларны үлчәүгә куячаксың. Кардәшем, син ничек уйлыйсың, үлчәүдә никадәрле гамәлләрең булыр икән? Кайсы гамәлләрең басып китәр икән? Син беләсеңме үзеңнең урыныңны? Иман бит инде ул үзе үк гамәл кылу. Пәйгамбәребез с.г.в. әйтте: намазы юкның иманы юк. Рамазан аенда бер әби яныма килә. «Хәзрәт, мин авырыйм, ураза тота алмыйм», - ди. Мин әйтәм, ураза тота алмасаң, фидия бир, димен. «Нәрсә соң ул?» - ди. Мин әйтәм, менә бер ярдәмгә мохтаҗ кешегә 6 мең сум фидия бирсәң, ураза өстеңнән төшәр, дим. Әби «хым...» диде дә борылып китеп барды. Без гел Аллаһ кушканнарны үтәмәскә сәбәп эзлибез. Кардәшләрем, эзләмик без сәбәпне, безгә нәрсә кушылган - шуны башкарыйк. Аллаһ ташламас безне. Хәстәренә керешсәк, исәнлеген дә бирер, намаз өчен гомеребезне дә яхшыртыр. Шайтан кубызына биеп җәннәтле булып булмас.

## РУХИ ХӘЗИНӘ

# Кеше – хәлифә

Әссәләмүгәләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!

“Бәкара” сүрәсенең 30нчы аятенең эчтәлеген кыскача аңлатырга тырышып карыйк. “Һәм синең Раббың фәрештәләргә әйтте: “Мин Җир өстендә кешене хәлифә итеп билгеләячәкмен.” Фәрештәләр гаҗәпләнеп: “Җир өстендә тәртипсезлек таратучы һәм кан түгүче кешене хәлифә итәсеңме?” – диде. Фәрештәләр, киләчәк Адәм нәселләре Җирдә бозыклык кылыр дип фаразлап, Раббыбызга шундый сорау бирделәр. Ләкин шул ук вакытта Аллаһның һәр кимчелектән пакь булуын искәртеп, аятьтә алар үз сүзләрен: “Без Сине мактап тәсбихләр әйтәбез”, – дип дәвам иттеләр. Аллаһ исә аларга болай диде: “Дөреслектә, Мин сез белмәгәнне беләм». Без бу аятьтән Аллаһның кешене Җиргә хәлиф итеп билгеләвен белдек. Коръән Кәримдә хәлиф сүзе тирән мәгънәдә килә. Җитәкче генә дию аз булыр. Кеше – Аллаһ нигъмәтләре белән Җирдә идарә итүче. Бу зур вазыйфа аңа ышанып тапшырылган. Ягъни Җир шарыбыз – безнең өчен Аллаһтан бирелгән әмәнәт. Әмәнәт – ул сакларга ышанып тапшырылган нәрсә. Димәк, без Җир шарыбызда һәр нәрсәдә рухи яктан да һәм матди яктан да тәртип сакларга бурычлы.

Аллаһ барлыкка китергән бар нәрсәләр кешегә хезмәт итә: кояшы, яңгыры, туфрагы, ут, сулар, файдалы казылмалар, агач һәм үсемлекләр, җәнлек һәм кошлар... Ул нигъмәтләрне санап бетергесез. Әйе, бу дөньядагы һә нәрсә, хәтта без үзебез дә – Аллаһныкы һәм иртәме-соңмы Аңа кайтарылачакбыз. Без, кешеләр, Җиргә Аллаһ тарафыннан билгеләнгән хәлиф буларак, бүләк ителгән дөнья нигъмәтләрен дөрес кулланабызмы? - Аңлы кешеләр дөрес кулланырга тырыша. Ләкин тулаем Җир шарыбызга карасак, хәлләр аянычлы. Кешелек бик күп экологик проблемалар тудырды! Җиребезнең һавасы, суы, туфрагы, ризыклары пычранды. Урманнар да күпләп киселә. Күпме җәнлекләр кеше аркасында юкка чыкты яки бетү куркынычы астында! Бүген җәнлекләр генә түгел, үзебез дә упкын алдында торабыз. Мисал өчен, чүп мәсьәләсен алыйк. Планетадагы һәр шәһәр янында гигант өемнәр күребез. Без ясаган бу “чүп таулары” күпме җир мәйданын биләп тора, һавага, суга, якында яшәүче халыкка никадәр зур зыян сала! Һәр кеше чүбен сортировка ясап ташласа, хәл яхшырыр иде. Кабул ителгәннәрен чүпне аерым җыя торган урыннарга илтеп бирергә иренмәскә кирәк. Хәзер, әлхәмдүлилләһ, күп җирләрдә пластик өчен аерым контейнерлар да тора. Җыеп шунда ташларга уңайлы. Һәммәбезгә дә төрле экологик акцияләрдә актив катнаша башлау кирәктер. Мәсәлән, пакетлар урынына озак куллана торган тукыма сумкалар йөртү, батарейкаларны, макулатураны аерым җыю. Үзеңә кирәк булмаган әйберләрне, яхшы халәттә булса, башкаларга бирергә була. Әйтик, тузмыйча кечерәйгән киемнәрне берәрсенә бүләк итәргә.

Җир шарыбызны һәлакәткә илтүче төп сәбәпләрнең берсе – ул кулланучанлыкның артуы (потребительство). Бүген без чамадан тыш куллану заманында яшибез. Һәм бу безнең буыннар өчен зур сынау. Дөнья малы артыннан куып, әмәнәт итеп бирелгән Җиребезне сакламый башладык. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең киләчәк буыннар өчен борчылып әйткән сүзләре бар. “Ярлылыктан курыкмыйм сезнең өчен, дөнья малына кызыгырсыз дип куркам, дөнья кулыгызга керер һәм чамасын югалтырсыз дип куркам”, – дигән ул. РасүлАллаһ бу вакытлы дөньяны – агач, ә кешеләрне шул агач күләгәсенә ял итәргә туктаган юлчы белән чагыштырган. Бу дөньяда яшәр өчен, кешегә мосафир юлга алган кадәр дә җитә. Күпмедер вакыттан соң һәр юлчы, матди гүзәллекләр, кызыктыргычлар белән тулган тормыш агачын калдырып, үз юлын дәвам итәчәк, мәңгелеккә Раббысы янына кайтачак. Димәк, булганыннан канәгать булып, исраф итмичә яшәргә, Җиребезне сакларга кирәк.

Кеше – Аллаһның Җирдәге хәлифәсе! Шушы бөек вазыйфаны һәрберебез куллыннан килгәнчә, җиренә җиткереп башкарырга бурычлы. Кулланган һәрбер нигъмәт өчен Аллаһ каршында җавап бирәсен онытмыйча, һәммәбезгә дә аңлы рәвештә яшәргә насыйп итсен Раббыбыз.

**Әлфия МӨДӘРИСОВА, мөгаллимә.**

## ӘДӘБИ СҮЗ

### Авырып китте кардәшем

Шуңа читкә куеп бар эшем,
Ашкындым тизрәк янына –
Тынгы салам диеп җанына.
Хәбәре бик шомлы булды,
Чарасыздан күңелем тулды...
Дустымның хәле авыррак:
Яман шеш таптылар, диде... рак...
Тиз килеп җиттем өенә.
Моңайды ул кайгы көенә:
- Шундый хәл... – диде аптырап,
- Көтмәгәндә булдым бит харап...
Шушылай гыйбрәт алганчы,
Уйлап карамадым моңарчы:
Яшәрмен озак янәсе,
Ә янымда – үлем шәүләсе...
... Дәшмичә утырдым әүвәл.
Дөрестән дә – шактый авыр хәл...
Күзләрендә тик бер сорау:
- Нигә миңа булды бу сынау?!
Нигә мин? Мин яшь бит әле!
Тормышның кызыклы һәр мәле...
Моңарчы яшәдем рәхәт,
Каян килеп чыкты бу зәхмәт?
... Карашым төбәп идәнгә,
Әйттем: Аллаһ безне сөйгәнгә
Саулыкны бирә һәм чирне –
Насыйп итеп тик хәерлене.
Аллаһның хөкеме кырыс,
Тик тәкъдиргә ышану – фарыз!
Раббыбыз кадир, шәфкатьле,
Ни бирсә дә – бул итагатьле.
Ирештеме сиңа зәхмәт –
Бел: монда нииндидер бар хикмәт.
Тоймасаң да җан рәхәте,
Авыру – Аллаһның рәхмәте.
Моңарчы ваемсыз булдың,
Онытылып, тик дөнья кудың,
Авыргач – исеңә төшә
Бөек Раббың... Ул сиңа дәшә:
- Күп чаптың инде, әй колым!
Үз-үзеңә кылдың күп золым:
Раббыңны искә алмыйча,
Күңелеңне дингә салмыйча,
Туры юлдан читкә китеп,
Кыйммәт вакытны әрәм итеп...
Бу дөнья – вакытлы торак,
Яшәп булмый монда бик озак,
Иң күбе – сиксән - туксан ел,
Соңыннан исә – мәңгелек... Бел!
Бу тормыш кайчандыр бетәр,
Һәммәбез ахирәткә китәр.
Шунысы зур әһәмият –
Яшәүнең максаты, төп ният...
Аллаһның бәндәсе булсаң,
Тормышның максатын аңласаң,
Күпме гомер бирелсә дә,
Бүген үлсәң дә, терелсәң дә,
Син инде бәхетле кеше –
Хәерлегә була һәр эшең!
“Нигә мин, ник миңа?” дисең,
Шушы хәлгә китмәсен исең!
Якынаерга Раббыңа
Ярдәм итә авыру... Шуңа
Кайгырма китте дип саулык,
Гыйбадәтсез үл – шикле байлык.
Аллаһның рәхмәте олы,
Тик Аның ихласлы бул колы.
Иң зур байлык – ихлас иман,
Аллаһның ярдәменә инан!
Биргәненә шөкер итсәң,
Ризалыгын алып яшәсәң,
Ярдәменнән Ул ташламас,
Авыр хәлдә сине калдырмас...
Ул моны бит вәгъдә итте,
Бер әйтүе дә безгә җитте.
Аңа тәвәккәлләп яшә,
Якын дус-туганнар – янәшә!
Шунысы да мөһим, кардәш:
Раббыңа син дога кылып дәш!
Саулык сорарга бар хакың,
Бел: Аллаһ һәрвакыт бик якын!
Теләсә – шифасын бирер,
Авыру дәвасын белдерер.
Юк икән – моны кабул ит,
Бу хөкемгә риза булып кит...
Аллаһка итагать итсәң,
Кабул итеп иманлы китсәң,
Кыены дөньяда калыр,
Ахирәттә әҗере булыр.
Барысын да була бирсәң,
Шул әҗернең кыйммәтен белсәң!
...Шулай да, син әле исән
Һәм нишлим икән хәзер дисәң,
Хаталарың барлап бөтен,
Аллаһыдан син гафу үтен.
Кем хакын боздың – бәхилләш,
Һәрберсе белән күреш, сөйләш,
Мөмкинлек булганда төзәт
Башкалар белән мөнәсәбәт.
Тәүбәгә кил. Кичер. Аңла...
Күңелеңне өметкә багла,
Ләкин бу дөньяга түгел –
Ахирәткә ашкынсын күңел!
Хак максат, чын бәхет анда –
Фәкать мәңгелек тормышында!
Иманлы кешене көтә
Искиткеч яшәеш Җәннәттә...
Раббыңа син ихлас ышан
Һәм зыян салмасын шайтан,
Нәфеснең кылына тиеп,
Гадел түгел бу хөкем, диеп.
Барысы алдан язылган,
Шайтан сүзе – вәсвәсә, ялган!
Шушы хәл – бары тик сынау
Тугрылыкка... Шуңа – бул уяу:
Раббыңа тугры булып кал,
Бу дөньяны корбан итеп «чал»!
Барысын Аллаһ хәл итә,
Бәхетле булырга Ул җитә...
...Күтәрде башын кардәшем
Һәм елмаеп сөртте күз яшен,
- Мең шөкер Раббыма! – диде,
- Мин бүтән кайгырмамдыр инде,
Аллаһым бар икән минем,
Туры юлны күрсәткән динем,
Аллаһтан ихлас сорармын,
Син әйткәнчә, дога кылырмын...
Ахыргы нәтиҗә – Аннан,
Мәрхәмәтле, юмарт Раббымнан.
Ни булса дә – кабул итәм...
Ә сине – иртәгә дә көтәм.
Килмәсәң – шалтырат, эндәш!
Ярый син бар әле, әй кардәш!
Зур рәхмәт: килеп яныма,
Нурлы бүләк салдың җаныма...
Аллаһның рәхмәте яусын,
Дуслыгыбыз мәңгелек булсын.

**Ришат КУРАМШИН,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире.**

## Кризис – Аллаһның хөкеме



“Элек тормыш намаз белән намаз арасында барса, хәзер сериал белән сериал арасында бара. Шуңа күрә ил дә кризис белән кризис арасында яши. “Кризис” сүзе грекчадан Аллаһ Тәгаләнең хөкеме дип тәрҗемә ителә. Коръәни Кәримдә “Шура” сурәсендә Аллаһ Тәгалә: “Мин ризыгымны бер киңәйтәм, бер тарайтам. Әгәр мин ризыгымны тигез генә бирсәм, Адәм баласы минем турыда оныта, бозыклык кыла башлый”, дип әйткән. Димәк, кризис җибәреп, Аллаһ Тәгалә Адәм баласының ризыгын кыса. Бу исә безнең яшәвебездә нәрсәдер дөрес түгел дигәнне аңлата.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые.**

## Тыйнак әүлия

Беркөнне урамнан барганда, Әбү Госман Һири хәзрәтләренең өстенә көл түккәннәр. Читкәрәк китеп, ул өстен-башын көлдән тазарткан да, болай дигән: «Мең шөкер, йә Раббы!». Ишетүчеләр килеп сораган: «Бөтен киемегез көлгә буялып бетте бит, моңа ничек шөкер итмәк кирәк?» «Әйе, шөкер итәм, чөнки Аллаһ чынлыкта мин гөнаһлы бәндәне утка куясы урынга, өстемә көл җибәрде. Моңа ничек итеп шөкер итмисең инде?» – дип җавап кайтара Әбү Госман.

## Виноград

Мөхәммәд пәйгамбәрне (с.г.в.) яраткан, бик тә хөрмәт иткән мөселманнар ничек тә аның күңелен күрергә, нинди дә булса яхшылык эшләргә тырышалар иде. Беркөнне Аллаһның рәсүле сәхабәләре белән бергә утырганда, аның янына фәкыйрь кыяфәтле бер ир килә. Кулында бер савыт виноград тотып торган бу бәндә, пәйгамбәрне күргәч, ничектер оялып, каушап кала, һәм килүенең максатын аңлатып:

- Әй рәсүлуллаh! Сиңа бирәр игелек эшләргә теләдем, шуңа күрә менә шушы виноградны күчтәнәч итеп алып килдем. Рәхим итеп кабул кылчы! – дип әйтә дә, калтыраган кулы белән савытны пәйгамбәр (с.г.в.с.) алдына куя.

Мөхәммәд салләллаһү галәйһи үә сәлләм баш ишарәсе илә рәхмәтен белдереп, бер виноград җимешен ашап куя да, елмаеп җибәрә. Шуны күргән ир дә елмая башлый. Соңыннан пәйгамбәр (с.г.в.с.) икенче җимешне ашый, аннан соң өченчесен, дүртенчесен, һәм һәр җимешне йоткан саен аның йөзен нурлы елмаю яктырта иде. Шулай итеп, Мөхәммәд салләллаһү галәйһи үә сәлләм бөтен виноградны ашап бетереп, савытын кире тапшыра, ә теге ир шатлыгын йөрәгенә сыйдыра алмыйча, бөтен әйләнә-тирәне бәхетле йөзе белән яктыртып, кайтып китә. Әмма сәхабәләр бу хәлгә бик аптырап калалар, чөнки башка вакытта Мөхәммәд галәйһиссәләмгә нинди генә ризык алып килсәләр дә, ул һәрвакытта иптәшләре белән бүлешә иде. Ә бу юлы бирелгән күчтәнәчне беркемгә дә тәкъдим итмичә, үзе генә ашады... Сәхабәләрнең берсе соңрак моның сәбәбен сорагач, Мөхәммәд салләллаһү галәйһи үә сәлләм болай җавап бирде:

- Бу ир кеше алып килгән виноград бик әче булып чыкты. Әгәр мин сезнең белән бүлешкән булсам, арагыздан берегез бу хакта әйтеп, виноградны алып килгән кардәшебезнең күңелен төшерер иде. Ә болай ул өенә бик шатланып кайтып китте...

**Ришат КУРАМШИН әзерләде.**

*Балалар өчен*

### Сөннәт гамәлләр

Безне тәрбияли торган,
Туры юлдан алып барган,
Бер Аллаһка сыендырган,
Була ул - сөннәт гамәлләр!
Безне гел үстерә торган,
Ялкаулыктан баш тарттырган,
Өстендә эшләргә кушкан,
Була ул - сөннәт гамәлләр!
Гөнаһлардан саклый торган,
Йөрәгебезгә нур салган,
Безләрне бәхетле кылган,
Була ул - сөннәт гамәлләр!

**Алинә ХӘБИБУЛЛИНА.**

## Кабак

**Саулыгым-байлыгым!**



Кабак файдалы матдәләргә бик бай. Кабакның йомшагы һәм төшләре, беренче чиратта, тәндәге су һәм тозлар алмашына йогынты ясый, бөерләрнең чистарту үзлеген көчәйтә, тәннән тиз арада хлоридларны чыгарырга ярдәм итә, ашказаны эшчәнлеген яхшырта, эч кибүләрне булдырмый. Иң беренче чиратта ул кан тамырлары кысылу, тазару, төрле йөрәк авырулары (бигрәк тә шешенүләр булса) сәбәпле кан тамырларына тоташтыргыч тукыма үсүдән газапланган кешеләргә ярдәм итә. Кабакның йомшагы һәм төшләре шикәр авыруы, үт куыгының дәвамлы ялкынсынуы вакытында, бөер тукымасы, ашказаны, нечкә һәм туры эчәк ялкынсынганда, тоз утыру авыруы күзәтелгәндә, йокысызлыктан интеккәндә, йөкле хатын-кызларда сыеклык тоткарланганда, яисә гормоннар балансы бозылганда ярдәм итә. Тән өшегәндә, пешкәндә, тире кызару авыруы күзәтелгәндә, яралар һәм шешле куыкчыклар булганда, кабакны уып, җәрәхәтле урынга куйсаң, ярдәм итми калмас. Халык та, табиблар да кабак нигезендә ясалган даруларны бөерләр, үт һәм бәвел куыгы авырулары вакытында, матдәләр алмашы бозылганда дәвалану һәм авыруларны булдырмау, шулай ук суалчаннарны куу чарасы буларак кулланалар.

Кабак йомшагы турап пешерелгән тары боткасына май, сөт, бал өстәп ашау үт куыгы авырулары вакытында бик файдалы.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**
* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *
Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**
**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**14 ноябрь 16 сәг.**
**фактта 14 ноябрь 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**